**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге составына керүче Калинин авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

22 ноябрь, 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 1 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар жыены нәтижәләре белән гражданнар жыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл жирлеге Калинин авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юлларны ремонтлау;
- янгын сүндерү машинасына гараж

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар жыены нәтижәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында катнашучы 83 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар жыенында катнашучылар саны –45 кеше.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча жыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар жыенында катнашучы 45 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен жыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Калинин авылында гражданнар жыенын узган, гражданнар жыены нәтижәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Калинин авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм

Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юлларны ремонтлау;
-янгын сүндерү машинасына гараж.

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Калинин авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Калинин авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев